Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Түбән Көчек торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**31.10.2025** **№ 1**

Гамәлдәге законнар нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына таянып, 2025 елның 31 октябрендә 10 сәгать 00 минутта “Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Түбән Көчек торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән (махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекleләр) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (ата-аналар, ирләре яки хатыннары), I төркем инвалидлардан, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге ялгыз гражданнардан, көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясенә хәрби хезмәткә чакырылган һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш), 2026 елда үзара салым акчасын 1000 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны җирлек өчен әһәмияте булган мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне:

1) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзекләндерү, карап тоту (Яңа урамына, Колхоз тыкрыгының 9-11 нче йортлар янында юлга салу өчен вак таш сатып алу һәм эшләтү, автомобиль юлларын карап тоту буенча башка чыгымнар).

2) Су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Буадан Калинин урамына су агызу торбалары сатып алу һәм урнаштыру, су башняларын тсту һәм хезмәт күрсәтү, насос будкасына ремонт һәм торак пунктында су белән тәэмин итү өчен башка чыгымнар);

3) Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (электротоварлар сатып алу һәм урам яктырткычларын урнаштыру, электрикка хезмәт хакы түләү, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка чыгымнар);

4) Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча беренчел чаралар күрү (янгын сүндерү машинасы тоту; ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча башка чыгымнар).

5) Һәйкәлләр кую һәм аларның янәшә-тирәсен төзекләндерү (Ленин урамында Тыл хезмәтчәннәренә һәйкәл эшләтү һәм куйдыру.

6) Торак пунктны төзекләндерү
-Түбән Көчек торак пункты юлларын кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәт килешүе буенча трактористка хезмәт хакы түләү;
- кыргый куаклыклар, агачларны эшкәртү һәм бетерү өчен гербицидлар сатып алу;
- авария хәлендәге һәм корыган агач-куакларны кисү, чүп үләннәрен чабу;

-МТЗ-82 тракторы тоту һәм хезмәт күрсәтү, башка чыгымнарга башкаруга юнәлтүгә, куллануга ризамы?" дигән сорау буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

« РИЗА» «КАРШЫ»

Беркетмә нигезендә гражданнар җыены нәтиҗәләре турында:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 418 катнашучы кертелде. Гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 236 кеше, бу 56,4% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенының 236 катнашучысы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирүчеләр юк.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды :

1.Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Түбән Көчек торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Әгерҗе муниципаль районы «Көчек авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Түбән Көчек торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән (махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгәннәр, ирекле хезмәткәрләр ) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (ата-аналары, ире яки хатыны), Iтөркем инвалидлардан, өлкән

яшьтәге ялгыз гражданнардан (80 яшькә җиткәннәрдән), көндезге формада укучы студентлардан, Россия армиясе сафларына хезмәткә чакырылган һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш) 2026 елда үзара салым акчаларын 1000 сум күләмендә кертергә.

3.Алынган акчаларны, җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтергә:

1) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзекләндерү, карап тоту (Яңа урамына, Колхоз тыкрыгының 9-11 нче йортлар янында юлга салу өчен вак таш сатып алу һәм эшләтү, автомобиль юлларын карап тоту буенча башка чыгымнар).

2) Су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Буадан Калинин урамына су агызу торбалары сатып алу һәм урнаштыру, су башняларынтоту һәм хезмәт күрсәтү, насос будкасына ремонт һәм торак пунктында су белән тәэмин итү өчен башка чыгымнар);

3) Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (электротоварлар сатып алу һәм урам яктырткычларын урнаштыру, электрикка хезмәт хакы түләү, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка чыгымнар);

4) Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча беренчел чаралар күрү (янгын сүндерү машинасы тоту; ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча башка чыгымнар).

5) Һәйкәлләр кую һәм аларның янәшә-тирәсен төзекләндерү (Ленин урамында Тыл хезмәтчәннәренә һәйкәл эшләтү һәм куйдыру.

6) Торак пунктны төзекләндерү
-Түбән Көчек торак пункты юлларын кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары сатып алу, хезмәт килешүе буенча трактористка хезмәт хакы түләү;
- кыргый куаклыклар, агачларны эшкәртү һәм бетерү өчен гербицидлар сатып алу;

- авария хәлендәге һәм корыган агач-куакларны кисү, чүп үләннәрен чабу;

-МТЗ-82 тракторы тоту һәм хезмәт күрсәтү, башка чыгымнар.

4. Карарны Көчек авыл җирлегенең мәгълүмат стендында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы сайтында (https://agryz.tatarstan.ru), «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
авыл җирлеге башлыгы Ә.Р. Төхфәтуллина